Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кичкетаң торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**01 ноябрь 2023** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның "01" ноябрендә 14 сәгать 00 минутта уткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Кичкетаң авыл җирлеге" Кичкетаң торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, ирегеннән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юлланган 2024 елда үзара салым чараларын кертү һәм куллану белән килешәсезме:

а) Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү системаларын, су манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (сууткәргечне алыштыру өчен материалларны ремонтлау, сатып алу).

б) Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау(дроссель лампаларын сатып алу һәм алмаштыру).

в) Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү (тракторны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, трактор өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу).

г) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу).

д) халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 342 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 200 кеше, бу 58,5 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 200 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. I төркем инвалидларыннан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән яшьтәге граждannардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ихтыярый затлар) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар), ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, 2024 елда “Кичкетаң авыл җирлеге” территориясенең Кичкетаң авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү системаларын, су манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (суүткәргечне алыштыру өчен материалларны ремонтлау, сатып алу).
- Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау(дроссель лампаларын сатып алу һәм алмаштыру).
- Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү (тракторны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, трактор өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу).
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу).

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы И.Н. Җиһангәрәев